СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

Тау өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

от 20 июнь 2023 ел — № 2-24

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге муниципаль милкенә карата концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Тауиле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Тауиле авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Тауиле авыл җирлеге башлыгы В.И.Ивановка йөкләргә.

Тауиле авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /В.И.Иванов/

СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001348

1 нче кушымта

Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | Наименование объекта | Кадастровый номер | Адрес местоположения (нас.пункт/ул.) | Техн.параметры (площадь/диаметр/высота/протяженность и т.д.) | Год ввода в эксплуатацию |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Суэтем башнясы | 16:26:600101:33 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы | Объем 8 куб.м. | 1985 |
| 2 | Суэтем башнясы | 16:26:600301:467 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы | тирәнлек 6.м. | 1972 |
| 3 | Су алу җайланмасы | 16:26:000000:4368 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы | Протяженность 2357 м. | 1985 |
| 4 | Су алу җайланмасы | 16:26:000000:4369 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Тауиле авылы | Протяженность 577 м. | 1972 |
| 5 | Суэтем башнясы | 16:26:600201:40 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Чаксы авылы | тирәнлек 9 м. | 1985 |
| 6 | Су алу җайланмасы | 16:26:000000:4372 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Чаксы авылы | Протяженность 2199 м. | 1985 |